РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02.12.2019 № 1628-п

Юридик затның, муниципаль берәмлекнең бюджет кредитын кире кайтару, процент һәм башка түләүләрне түләү буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә бирелә торган банк гарантиясенең, җаваплылыкны өскә алуның ышанычлылыгын бәяләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 932 маддәсенең 3 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Юридик затның, муниципаль берәмлекнең бюджет кредитын кире кайтару, процент һәм башка түләүләрне түләү буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә бирелә торган банк гарантиясенең, җаваплылыкны өскә алуның ышанычлылыгын бәяләү тәртибен расларга.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Җитәкче М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
______________________
______________________
номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Юридик затның, муниципаль берәмлекнең бюджет кредитын кире кайтару, процент һәм башка түләүләрне түләү буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә бирелә торган банк гарантиясенең, җаваплылыкны өскә алуның ышанычлылыгын бәяләү Тәртибе**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексының 932 маддәсендәге 3 пункты нигезендә эшләнде һәм юридик затның, муниципаль берәмлекнең бюджет кредитын кире кайтару, процент һәм башка түләүләр буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә бирелә торган банк гарантиясе һәм җаваплылыкны өскә алуның ышанычлылык күрсәткечләрен билгели.

1.2 Банк гарантиясе һәм җаваплылыкны өскә алуның ышанычлылыгы банк яисә башка кредит оешмасының (алга таба - гарант) һәм җаваплылыкны өстенә алучының финанс тотрыклылыгы белән билгеләнә.

1.3 Банк гарантиясе һәм җаваплылыкны өскә алуның ышанычлылыгы дигәндә, әлеге Тәртип максатларында гарант һәм җаваплылыкны өстенә алучының бюджет кредитын кире кайтару буенча юридик зат, муниципаль берәмлек (алга таба – алучы) йөкләмәләрен үз вакытында һәм тулы күләмдә үти алуы аңлашыла.

1.4 Тәэмин итү күләме, бирелә торган бюджет кредиты күләмен, аның буенча процентларны һәм тиешле килешүдә каралган башка түләүләрне капларга тиеш.

1.5 Йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итүне рәсмиләштерү Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетыннан бюджет кредиты бирелгәнче башкарыла.

1.6. Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы (алга таба – Финорган) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджетыннан тәэмин итүгә бирелә торган бюджет кредитларын, банк гарантиясен һәм җаваплылыкны өскә алуны бәяләүне башкара.

2. Банк гарантиясенең ышанычлылыгын бәяләү

2.1. Әлеге Тәртип максатларында гарант түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

– юкка чыгу, үзгәртеп кору, банкротлык процессында булмау;

– административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган тәртиптә эшчәнлек туктатылмавы;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча кичектерелгән (җайга салынмаган) бурыч булмау, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурыч, шулай ук Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы тарафыннан элегрәк бирелгән муниципаль гарантияләр буенча җайга салынмаган йөкләмәләр булмау;

– Банк операцияләрен башкаруга Россия Федерациясе Үзәк банкының генераль лицензиясе булу;

– “Россия Федерациясе банкларында кертемнәрне иминләштерү турында” 2003 елның 23 декабрендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе банкларында физик затларның кертемнәрен мәҗбүри иминиятләү системасында катнашу (Россия банкының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында соңгы хисап датасына урнаштырылган рәсми мәгълүматлар);

– Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан “Россия Федерациясе Үзәк банкы турында (Россия Банкы).” 2002 елның 10 июлендәге 86-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән мәҗбүри нормативларны бозган өчен чаралар кулланылмаган (Россия Федерациясе Үзәк банкының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында соңгы хисап датасына урнаштырылган рәсми мәгълүматлар).

2.2. Әлеге тәртипнең 2.1. пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган Гарант Финанс органына түбәндәге документларны тәкъдим итә:

а) гарантның алучы йөкләмәләре буенча гарант буларак чыгыш ясарга ризалыгы турында хаты;

б) гарантның үзе тарафыннан расланган гамәлгә кую документлары күчермәләре;

в) салым органында исәпкә кую турында таныклык, дәүләт теркәвенә алу турында таныклык яки гарант тарафыннан расланган юридик затларның бердәм дәүләт реестрын язу кәгазе күчермәләре;

г) гарантның юкка чыгу, үзгәртеп кору, банкротлык процессында булмавын раслаучы документлар;

д) гарантның бердәм башкарма органы, башка вәкаләтле затның Гарант исеменнән килешүләр эшләүгә вәкаләтләрен раслаучы документлар һәм гарантның баш хисапчысы (сайлау турында карар, билгеләп кую турында боерык, вазыйфага керү турында боерык, контракт күчермәсе, ышаныч кәгазе), шулай ук гарант раслаган нотариаль расланган култамга үрнәкләре һәм Гарант мөһере оттискасы;

е) банк гарантиясен бирү буенча алыш-бирешләр ясаганда (алучының йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү өчен) гарант идарәсенең вәкаләтле органы тарафыннан килешүне (хуплауны) раслый торган документның нотариаль расланган күчермәсе;

ж) банк операцияләрен башкару өчен Россия Федерациясе Үзәк банкының генераль лицензиясенең нотариаль расланган күчермәсе;

з) соңгы хисап датасына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча гарантның бурычлары булмавын раслаучы салым органы белешмәсе;

и) хисап финанс елы өчен һәм соңгы хисап датасына гарант раслаган бухгалтерлык балансы һәм керемнәр һәм чыгымнар турында хисап;

к) әлеге Тәртипнең 2.2 пунктының “а” пунктчасы нигезендә хат белән мөрәҗәгать иткән елга гарантның бухгалтерлык хисаплылыгының дөреслеге турында Гарант раслаган аудиторлык бәяләмәсе күчермәсе;

л) Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнә торган форма буенча гарантның үз акчаларын (капиталын) исәпләү һәм, рөхсәт ителгән күрсәткечләр диапазонын китереп, соңгы хисап датасына мәҗбүри нормативлар күрсәткечләре;

м) Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнә торган форма буенча мәҗбүри нормативлар турында мәгълүмат;

н) Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнә торган форма буенча Гарант активларының сыйфаты турында мәгълүмат;

о) җитәкче кул куйган һәм Гарант мөһере белән расланган гарантның чиста активларын исәпләү;

п) Россия Федерациясе Үзәк банкының соңгы ярты ел дәвамында мәҗбүри резерв таләпләренең үтәлеше турында, клиентларның исәп-хисап документларын вакытында түләмәү фактларының булмавы турында, Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан гарантка карата кулланылган мәҗбүри йогынты чаралары булмау турында Россия Федерациясе Үзәк банкы белешмәсе;

р) Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан вәкаләтле вазыйфаи затлар кандидатураларын килештерүне раслый торган документлар

Гарант әлеге пунктның «в», «г», «з» пунктчаларында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Финанс органы аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

2.3. Гарантның финанс хәле түбәндәге күрсәткечләр ярдәмендә билгеләнә:

соңгы финанс елына һәм агымдагы елның узган чорына зыяннар булмау;

гарантның I һәм II категория сыйфатлы активлары гомуми активларның кимендә 50 процентын тәшкил итәргә тиеш;

гарантның Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнгән мәҗбүри нормативларга туры килүе;

гарантның чиста активлары күләме бирелгән бюджет кредитының өч тапкырга тигез суммасы күләменнән ким булырга тиеш түгел.

2.4. Гарантның Финанс органына кергән документлары алар кергән көнне теркәлә.

2.5. Гарант тарафыннан тапшырылган документлар әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында билгеләнгән документлар исемлегенә туры килмәгән очракта, Финанс органы, документларны теркәү датасыннан биш эш көненнән дә соңга калмыйча, аларны кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, гарантка кире кайтара.

2.6. Гарант тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында билгеләнгән исемлегенә туры килгән очракта, Финанс органы банк гарантиясенең ышанычлылыгына бәя бирә. Финанс органы тапшырылган документларны, документларны теркәү датасыннан алып, эш көннәрендә гарантның әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында каралган таләпләргә туры килү-килмәвен һәм, әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләрне исәпкә алып, аның финанс хәлен билгеләүне күздә тота.

Документларны карау нәтиҗәләре буенча Финанс органы гарантның финанс тотрыклылыгы һәм аның бюджет кредитын кире кайтару буенча алучының йөкләмәләрен үз вакытында һәм тулы күләмдә үтәү сәләте турында бәяләмә әзерли, бу хакта гарантка Бәяләмәне әзерләү датасыннан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

3. Җаваплылыкны өскә алуның ышанычлылыгын бәяләү

3.1. Әлеге Тәртип максатларында җаваплылыкны өстенә алучы түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

юкка чыгу, үзгәртеп кору, банкротлык процессында булмау;

административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган тәртиптә эшчәнлек туктатылмавы;

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча кичектерелгән (җайга салынмаган) бурыч булмау, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурыч, шулай ук Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы тарафыннан элегрәк бирелгән муниципаль гарантияләр буенча җайга салынмаган йөкләмәләр булмау;

3.2. Әлеге тәртипнең 3.1. пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган җаваплылыкны өстенә алучы Финанс органына түбәндәге документларны тәкъдим итә:

а) җаваплылыкны өстенә алучының йөкләмәләр буенча җаваплылыкны өстенә алучы буларак чыгыш ясарга ризалыгы турында хаты;

б) җаваплылыкны өстенә алучының үзе тарафыннан расланган гамәлгә кую документлары күчермәләре;

в) салым органында исәпкә кую турында таныклык, дәүләт теркәвенә алу турында таныклык яки җаваплылыкны өстенә алучы тарафыннан расланган юридик затларның бердәм дәүләт реестрын язу кәгазе күчермәләре;

г) җаваплылыкны өстенә алучының бердәм башкарма органы, башка вәкаләтле затның җаваплылыкны өстенә алучы исеменнән килешүләр эшләүгә вәкаләтләрен раслаучы документлар һәм җаваплылыкны өстенә алучының баш хисапчысы (сайлау турында карар, билгеләп кую турында боерык, вазыйфага керү турында боерык, контракт күчермәсе, ышаныч кәгазе), шулай ук нотариаль расланган култамга үрнәкләре һәм җаваплылыкны өстенә алучы мөһере оттискасы;

д) җаваплылыкны өскә алу буенча алыш-бирешләр ясаганда (алучының йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү өчен) җаваплылыкны өстенә алучы

идарәсенең вәкаләтле органы тарафыннан килешүне (хуплауны) раслый торган документның нотариаль расланган күчермәсе;

е) җаваплылыкны өстенә алучының юкка чыгу, үзгәртеп кору, банкротлык процессында булмавын раслаучы документлар;

ж) җаваплылыкны өстенә алучы тарафыннан хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиянең нотариаль яктан расланган күчермәсе (Россия Федерациясе законнары белән җаваплылыкны өстенә алучы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшчәнлекнең лицензия нигезендә гамәлгә ашырылуы билгеләнгән очракта);

з) җаваплылыкны өстенә алучының кредит оешмаларында ачылган гамәлдәге счетлары турында салым органы тарафыннан расланган белешмә;

и) җаваплылыкны өстенә алучының исәп-хисап счетларында акчалар булу һәм аларга картотека суммасы турында банклар тарафыннан бирелгән белешмәләр;

к) төп чаралар, тәмамланмаган төзелеш, матди кыйммәтләргә керемнәр, озак сроклы финанс кертемнәре, кыска сроклы финанс кертемнәре, дебитор бурычлары, озак сроклы бурычлар, кыска сроклы кредитлар һәм займнар, кредит бурычлары турында баланс статьяларының расшифровкаларын кушып, (һәр төр бурыч буенча), җаваплылыкны өстенә алучы тарафыннан расланган, аларны кабул итү турында салым органы тамгасы белән, аларга аңлатма язулары белән бухгалтерлык балансы, хисап финанс елына һәм соңгы хисап датасына  финанс нәтиҗәләре турында хисап ;

л) салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә соңгы хисап датасына түләнергә тиешле  салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча җаваплылыкны өстенә алучының бурычлары булмавын раслаучы салым органы белешмәсе;

м) әлеге Тәртипнең 3.2 пунктының «а» пунктчасы нигезендә хат белән мөрәҗәгать иткән ел эчендә җаваплылыкны өстенә алучының бухгалтерлык хисаплылыгының дөреслеге турында аудиторлык бәяләмәсе күчермәсе (Россия Федерациясе законнары нигезендә ел саен аудиторлык тикшерүе узарга тиешле юридик затлар өчен);

н) җитәкче кул куйган һәм җаваплылыкны өстенә алучы мөһере белән расланган җаваплылыкны өстенә алучының чиста активларын исәпләү.

3.1. Җаваплылыкны өстенә алучы әлеге пунктның «в», «е», «л» пунктчаларында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Финанс органы аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

3.2. Финанс органына кергән җаваплылыкны өстенә алучының документлары алар кергән көнне теркәлә.

3.3. Җаваплылыкны өстенә алучы тарафыннан тапшырылган документлар әлеге Тәртипнең 3.2 пунктында билгеләнгән документлар исемлегенә туры килмәгән очракта, Финанс органы, документларны теркәү датасыннан биш эш көненнән дә соңга калмыйча, аларны кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, җаваплылыкны өстенә алучыга кире кайтара.

3.4. Җаваплылыкны өстенә алучы тарафыннан тапшырылган

документларның әлеге Тәртипнең 3.2 пунктында билгеләнгән исемлегенә туры килгән очракта, Финанс органы тарафыннан җаваплылыкны өскә алуның ышанычлылыгына бәя бирелә. Финанс органы тапшырылган документларны, документларны теркәү датасыннан алып, эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көнлек срокта җаваплылыкны өстенә алучының әлеге Тәртипнең 3.1 пунктында каралган таләпләргә туры килү-килмәве предметына карый һәм җаваплылыкны өстенә алучының финанс хәлен әлеге тәртипнең кушымтасында нигезендә җаваплылыкны өстенә алучының финанс хәлен  бәяләү методикасы нигезендә анализлый.

Бюджет кредитын кайтару буенча йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итү буенча җаваплылыкны өстенә алучылар булып торучы юридик затларның финанс хәлен анализлау, бюджет кредитын алучыга бирү турында Карар кабул ителгән көнгә, күрсәтелгән юридик затларның рейтингы “Фитч Рейтингс” (Fitch Ratings) яки “Стандарт энд Пурс” (Standard & Poor 's) рейтинг агентлыклары классификациясе буенча “bb –” рейтингыннан ким булмаган яисә “Мудис Инвесторс Сервис” (Moody' s Investors Service) рейтинг агентлыгы классификациясе буенча “bb –” рейтингыннан ким булмаган очракта( рейтинг агентлыкларының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә аларның сайтларында урнаштырылган рәсми мәгълүматлары) үткәрелмәскә мөмкин.

Документларны карау нәтиҗәләре буенча Финанс органы җаваплылыкны өстенә алучының финанс тотрыклылыгы һәм аның бюджет кредитын кире кайтару буенча алучының йөкләмәләрен үз вакытында һәм тулы күләмдә үтәү сәләте турында бәяләмә әзерли, бу хакта җаваплылыкны өстенә алучыга бәяләмәне әзерләү датасыннан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

Юридик зат, муниципаль берәмлекнең бюджет кредитын кире кайтару, процент һәм башка түләүләрне түләү буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә бирелә торган банк гарантиясенең, җаваплылыкны өскә алуның ышанычлылыгын бәяләү тәртибенә Кушымта

## Җаваплылыкны өстенә алучының финанс хәлен бәяләү методикасы

**1. Җаваплылыкны өстенә алучының финанс хәлен бәяләү өчен финанс индикаторларының өч төркеме кулланыла:**

ликвидлык коэффициентлары;

үз һәм заем акчалары нисбәте коэффициенты ;

рентабельлек күрсәткече.

Исәп-хисап киләсе башлангыч мәгълүмат нигезендә башкарыла:

1 форма (бухгалтерлык балансы);

2 форма (финанс нәтиҗәләре турында хисап).

**2. Ликвидлык коэффициентлары**

2.1. Ликвидлык коэффициентлары төркеме өч күрсәткечтән тора:

абсолют ликвидлык коэффициенты;

тиз ликвидлык коэффициенты;

агымдагы ликвидлык коэффициенты.

2.2. К1 абсолют ликвидлыгы коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$К1=\frac{акчалар\ (1250)+кертемнәр\ (1240)}{йөкләмәләр\ (1500-1530-1540)},$$

монда:

акчалар - кассада һәм исәп-хисап счетындагы акчалар (балансның 1250 юлы);

кертемнәр-хисап чоры ахырына алынган кыска сроклы финанс чыгымнары (акцияләр, вексельләр, облигацияләр, бирелгән займнар һ.б.) суммасы. Аларга мөрәҗәгать итү (түләү) вакыты хисап датасыннан яки операция циклының дәвамлылыгыннан соң 12 айдан артмаган кертемнәр керә (балансның 1240 юлы);

йөкләмәләр-хисап датасыннан соң 12 айдан да ким булмаган вакытка җаваплылыкны өстенә алучының кыска вакытлы финанс йөкләмәләре. Кыйммәте V баланс бүлегенең нәтиҗәсе ( 1500 юл), киләчәк чорларның керемнәре (1530 юл) һәм бәяләү йөкләмәләренең (1540 юл) аермасы буларак тора.

2.3. К2 тиз ликвидлык коэффициенты хуҗалык әйләнешеннән акчаны оператив рәвештә азат итү һәм булган финанс йөкләмәләрен түләү

мөмкинлеген күрсәтә. Күрсәткеч түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$К2 = \frac{\text{бурычлар}(1230)+\text{кертемнәр}\ (1240)+\text{акчалар}\ (1250)}{\text{йөкләмәләр}\ (1500-1530-1540)},$$

монда:

деб.бурыч-дебитор бурычы, аны түләү ел дәвамында башкарыла (балансның 1230 юлы);

кертемнәр-хисап чоры ахырына алынган кыска сроклы финанс чыгымнары (акцияләр, вексельләр, облигацияләр, бирелгән займнар һ.б.) суммасы. Аларга мөрәҗәгать итү (түләү) вакыты хисап датасыннан яки операция циклының дәвамлылыгыннан соң 12 айдан артмаган кертемнәр керә (балансның 1240 юлы);

акчалар - кассада һәм исәп-хисап счетындагы акчалар (балансның 1250 юлы);

йөкләмәләр-хисап датасыннан соң 12 айдан да ким булмаган вакытка җаваплылыкны өстенә алучының кыска вакытлы финанс йөкләмәләре Кыйммәте V баланс бүлегенең нәтиҗәсе ( 1500 юл), киләчәк чорларның керемнәре (1530 юл) һәм бәяләү йөкләмәләренең (1540 юл) аермасы буларак тора.

2.4. К3 агымдагы ликвидлык коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$К3 = \frac{\text{әйләнештәге активлар}\ (1230)}{\text{йөкләмәләр}\ (1500-1530)},$$

монда:

әйләнештәге активлар - әйләнештәге активлар (1200 юл);

йөкләмәләр-хисап датасыннан соң 12 айдан да ким булмаган вакытка җаваплылыкны өстенә алучының кыска вакытлы финанс йөкләмәләре. Кыйммәте V баланс бүлегенең нәтиҗәсе ( 1500 юл) һәм киләчәк чорларның керемнәре (1530 юл) аермасы буларак тора.

**3. Үз һәм заем акчаларының нисбәте коэффициенты**

К4 нең үз һәм заем акчалары нисбәте коэффициенты түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$К4 = \frac{\text{үз капиталы}\ (1230)}{\text{заем капиталы}(1500+1400-1530)},$$

Монда:

үз капиталы-үз капиталы һәм резервлары (1300 юл);

заем капиталы-финанс бурычлары. Кыйммәте буларак чорларның керемнәрен исәпкә алмыйча (балансның 1530 юлы) кыска сроклы һәм озак сроклы йөкләмәләр суммасы тора.

## 4. Рентабельлек күрсәткече

4.1. Рентабельлек күрсәткече түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$К5 = \frac{\text{сатудан табыш (2200)}}{\text{сатудан керем(2110)}},$$

монда:

сатудан кергән табыш-продукцияне сатудан табыш (финанс нәтиҗәләре турында хисапның 2200 юлы);

керем-керем (финанс нәтиҗәләре турында хисапның 2110 юлы).

## 5. Финанс хәлен бәяләүне төзү

5.1. Һәр база индикаторы өчен иң яхшы һәм иң начар чикле кыйммәтләр билгеләнә.

5.2. Алынган кыйммәткә һәм иң чик күрсәткечләргә нигезләнеп, һәр күрсәткеч өчен өч категориянең берсе билгеләнә. Күрсәткечләрнең иң чик күрсәткечләре һәм күрсәткечләрнең факттагы кыйммәтләренә карап категорияне сайлау кагыйдәсе 1 таблицада китерелгән.

1 Таблица. Күрсәткечләрнең иң чик күрсәткечләре һәм күрсәткечләрнең факттагы кыйммәтләренә карап категорияне сайлау

| Коэффициентлар | 1 категория (күрсәткечнең яхшы кыйммәте) | 2 категория (күрсәткечнең канәгатьләнерлек кыйммәте) | 3 категория (күрсәткечнең канәгатьләнерлек булмаган кыйммәте) |
|---|---|---|---|
| $К_1$ | 0,2 дән күбрәк | 0,1 - 0,2 | 0,1 дән әзрәк |
| $К_2$ | 0,8 дән күбрәк | 0,5 - 0,8 | 0,5 тән әзрәк |
| $К_3$ | 2,0 дән күбрәк | 1,0 - 2,0 | 1,0 дән әзрәк |
| Коэффициентлар | 1 категория (күрсәткечнең яхшы кыйммәте) | 2 категория (күрсәткечнең канәгатьләнерлек кыйммәте) | 3 категория (күрсәткечнең канәгатьләнерлек булмаган кыйммәте) |
| $К_4$ | | | |
| сәүдә предприятиеләре | 0,6 дан күбрәк | 0,4 - 0,6 | 0,4 тән әзрәк |
| башка тармак | 1,0 дән күбрәк | 0,7 - 1,0 | 0,7 дән әзрәк |

| | | | |
|---|---|---|---|
| предприя тиеләре | | | |
| $К_5$ | 0,15 тән күбрәк | 0,0 - 0,15 | 0,0 әзрәк (рентабель түгел) |

5.3. Җыелма бәянең (S) кыйммәте түбәндәге формула буенча билгеләнә:

S = Авырлык1 х Категория1 + Авырлык2 х Категория2 + Авырлык3 х Категория3+ Авырлык4 х Категория4 + Авырлык5 х Категория5

Монда:
Авырлык і - җыелма бәяләүдә Кі күрсәткеченең авырлыгы, і = 1, 2, 3, 4 яки 5.
Күрсәткеч авырлыгы кыйммәте 2 таблицада тәкъдим ителгән .
Категория і - Кі күрсәткеченең кыйммәте карый торган категория.
Категория: 1, 2 яки 3.

2 Таблица. Җыелма бәяне исәпләгәндә кулланыла торган күрсәткечләрнең авырлыгы

| Күрсәткеч | Күрсәткеч авырлыгы |
|---|---|
| К1 абсолют ликвидлык коэффициенты | 0,11 |
| К2 тиз ликвидлык коэффициенты | 0,05 |
| К3 агымдагы ликвидлык коэффициенты | 0,42 |
| К4 үз һәм заем акчалары нисбәте | 0,21 |
| К5 рентабельлек коэффициенты | 0,21 |

5.4. Җыелма бәянең кыйммәте нигезендә җаваплылыкны өстенә алучының финанс хәле:
җыелма бәянең кыйммәте 1,05 тән артмаса, яхшы булып тора;
җыелма бәянең кыйммәте 1,05 тән артык булмаса һәм 2,4 тән артмаса, канәгатьләнерлек була;
җыелма бәянең кыйммәте 2,4 дән артып китсә, канәгатьләнерлек булмый.
Җаваплылыкны өстенә алучының чиста активлары күләме бирелгән бюджет кредитының өч тапкырга тигез суммасы күләменнән әзрәк булырга тиеш түгел.